# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка ав. торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

02 декабрь, 2019 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- Чернышевка авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Чернышевка авылындагы күп фатирлы йортларның йорт яны территориясен коймалар кую.;

- Чернышевка авылы җирләнгән урынга килү юлын төзекләндерү, Күмү урыннарын коймаларга ;

- Чернышевка авылы эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2019 елның 8 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2019 елның 15 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыеннарының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 829 (алтмыш ике) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 433 кеше, бу 52,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 298 (ике йөз туксан сигез) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 135 (утыз биш) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең Чернышевка ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) суммада үзара салым акчаларын кертергә. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- Чернышевка авылында урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Чернышевка авылындагы күп фатирлы йортларның йорт яны территориясен коймалар кую.;

- Чернышевка авылы җирләнгән урынга килү юлын төзекләндерү, Күмү урыннарын коймаларга ;

- Чернышевка авылы эчендәге юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче А. К. Җамалиев

Чернышевка авыл җирлеге башлыгы О.А.Маланин